ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.02.2021 с. Муслюмово 72

**«Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 21 августындагы 518 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең, Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына көтелгән үтәлеш йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия Беркетмәсен үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 30 сентябрендәге 1140 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарына туры китереп, Мөслим муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 21 августындагы 518 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.4 пунктка түбәндәге абзацны өстәргә: «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең, Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына көтелүче үтәлеш йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия Беркетмәсе»;

1.2 2.6 пунктына түбәндәге пунктчаны өстәргә: «7. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә (белешмәләр)»;

1.3. 2.9 пунктына түбәндәге пунктчаны өстәргә: «11. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч юклыгы турында белешмә (белешмәләр) булмау».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны инфраструктура үсеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе Р.Т.Демидов**